СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2020 г.Зеленодольск № 31

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 27 мартындагы 514 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләр тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (2019 елның 8 августындагы 421 номерлы ЗМР Советы карары белән расланган үзгәрешләр белән)

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон (2020 елның 20 июлендәге ред.), Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 27 мартындагы 514 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенең (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 8 августындагы 421 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) 5.2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.2.Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, рәсми басылып чыкканнан соң, үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ИНН 1648017831 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ